**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 27 май № 313

г. Казань

«Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын үткәрү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсы турында» 2016 ел, 18 август, 815 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын үткәрү турында нигезләмәне;

«Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын оештыру һәм үткәрү буенча республика комиссиясе составын.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына әлеге карар белән расланган Нигезләмә нигезендә «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабында шәһәр округлары, шәһәр һәм авыл җирлекләре катнашуы буенча эшне оештырырга тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.

4. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\313.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 27 май, 313 нче карары белән расланды

**«Иң яхшы муниципаль практика»**
**бөтенроссия конкурсының республика этабын үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын (алга таба – конкурс) үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Конкурсның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының муниципаль идарәне оештыру һәм муниципаль берәмлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча эшчәнлегенең иң яхшы практикасы үрнәкләрен билгеләү һәм сайлап алу;

«Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының федераль этабында катнашу өчен конкурста җиңүчеләрнең конкурс заявкаларын җибәрү.

1.3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү буенча эш түбәндәге принципларга нигезләнә:

ачык булу;

конкурста катнашучыларның тигезлеге;

конкурста катнашучылар хәл итә торган проблемаларның социаль әһәмияте.

1.4. Конкурс муниципаль идарәне оештыру һәм муниципаль берәмлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү практикасын чагылдырган түбәндәге номинацияләр буенча ел саен үткәрелә:

«Шәһәр төзелеше сәясәте, халыкның тереклек эшчәнлеге өчен уңай мохит тәэмин итү һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү»;

«Муниципаль икътисадый сәясәт һәм муниципаль финанслар белән идарә итү»;

«Муниципаль берәмлекләрдә яшәүчеләр белән нәтиҗәле «кара-каршы элемтә» тәэмин итү, территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерү һәм гражданнарны башка формалардагы җирле үзидарәне гамәлгә ашыруга (гамәлгә ашыруда катнашуга) җәлеп итү».

1.5. Конкурска материаллар әзерләү муниципаль берәмлекләр тарафыннан түбәндәгеләр катнашында гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы – «Шәһәр төзелеше сәясәте, халыкның тереклек эшчәнлеге өчен уңай мохит тәэмин итү һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү» номинациясе буенча;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән берлектә – «Муниципаль икътисадый сәясәт һәм муниципаль финанслар белән идарә итү» номинациясе буенча;

«Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән берлектә – «Муниципаль берәмлекләрдә яшәүчеләр белән нәтиҗәле «кара-каршы элемтә» тәэмин итү, территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерү һәм гражданнарны башка формалардагы җирле үзидарәне гамәлгә ашыруга (гамәлгә ашыруда катнашуга) җәлеп итү» номинациясе буенча.

1.6. Конкурста катнашучыларның түбәндәге категорияләре буенча бүленә торган шәһәр округлары, шәһәр һәм авыл җирлекләре конкурста катнашырга хокуклы:

а) I категория – шәһәр округлары һәм шәһәр җирлекләре;

б) II категория – авыл җирлекләре.

## II. Конкурс комиссиясенең һәм ярдәмче комиссияләрнең эшләү тәртибе

2.1. Конкурсны үткәрү максаты белән «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын оештыру һәм үткәрү буенча республика комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) төзелә.

Конкурс комиссиясе составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2.2. Конкурс комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

2.3. Конкурс комиссиясе билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

2.4. Конкурс комиссиясенең төп функцияләре булып түбәндәгеләр тора:

а) муниципаль берәмлекләрнең конкурс заявкаларын һәр номинация һәм конкурста катнашучыларның категориясе буенча анализлау;

б) ярдәмче комиссияләр составларын һәм алар турындагы нигезләмәләрне раслау;

в) конкурста җиңүчеләрне билгеләү;

г) конкурсны оештыру һәм үткәрү буенча башка мәсьәләләрне хәл итү.

2.5. Конкурс комиссиясе составына конкурс комиссиясе рәисе, рәистәше һәм әгъзалары керә.

2.6. Конкурс комиссиясе утырышында исемлек буенча составының кимендә өчтән бере катнашса, ул хокуклы санала.

2.7. Конкурс комиссиясе әгъзалары утырышларында алыштыру хокукыннан башка катнаша. Утырышта булмаган очракта, конкурс комиссиясе әгъзасы карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма формада бәян итәргә хокуклы.

2.8. Конкурс комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм аларга утырышта катнашучы әгъзаларның 50 процентыннан күбесе тавыш

бирсә, кабул ителгән булып санала. Тавышлар тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч санала.

Кабул ителгән карар белән риза булмаганда конкурс комиссиясе әгъзасы карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча үзенең аерым фикерен язма формада бәян итәргә хокуклы, ул утырышта белдерелә һәм беркетмәгә теркәлә.

2.9. Конкурс комиссиясе карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә һәм конкурс комиссиясе утырышын үткәргән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары тарафынан имзалана.

2.10. Конкурс комиссиясе беркетмәләре аларга кул куйган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясенең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш. Конкурс нәтиҗәләре буенча йомгаклау беркетмәсе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелә.

2.11. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән берлектә, «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән берлектә алар арасында бүленгән конкурс номинацияләре нигезендә ярдәмче комиссияләр формалаштыра, һәм алар:

а) конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник тәмин итүне гамәлгә ашыра;

б) конкурс комиссиясенә бирелә торган муниципаль берәмлекләрнең конкурс заявкаларын кабул итү һәм карап тикшерүне башкара;

в) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына конкурсны оештыру һәм үткәрү мәсьәләләре буенча мәгълүмат җиткерә;

г) муниципаль берәмлекләрнең тапшырылган конкурс заявкалары буенча мәгълүмат соратып ала һәм аңлатмалар ала;

д) конкурс заявкаларында тиешле конкурс номинацияләре буенча иң яхшы муниципаль практика үрнәкләре чагылыш тапкан муниципаль берәмлекләрне билгели.

## III. Конкурсны оештыру һәм аны үткәрү тәртибе

3.1. Конкурсны үткәрү турында мәгълүмат, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсы турында» 2016 ел, 18 август, 815 нче карары нигезендә Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы һәм Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан расланган муниципаль берәмлекләрнең конкурс заявкаларын бәяләү методикасын һәм муниципаль берәмлекләрнең конкурс заявкалары формасын кертеп, әлеге Нигезләмәнең 2.11 нче пунктында күрсәтелгән органнарның рәсми сайтларында 25 майдан да соңга калмыйча урнаштырыла.

3.2. Конкурсны оештыру һәм үткәрү турындагы мәгълүматта түбәндәгеләр күрсәтелә:

конкурсның исеме;

номинацияләр һәм конкурста катнашучылар категорияләре исеме;

конкурс заявкаларын кабул итүне башлау һәм тәмамлау көне һәм вакыты;

конкурс заявкаларын кабул итү урыны, элемтә өчен телефоннар һәм башка мәгълүмат.

3.3. Муниципаль берәмлекләрнең конкурс заявкалары 25 майдан башлап 15 июньгә кадәр тапшырыла:

а) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына – «Шәһәр төзелеше сәясәте, халыкның тереклек эшчәнлеге өчен уңай мохит тәэмин итү һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү» номинациясе буенча;

б) Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән берлектә – «Муниципаль икътисадый сәясәт һәм муниципаль финанслар белән идарә итү» номинациясе буенча;

в) «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән берлектә – «Муниципаль берәмлекләрдә яшәүчеләр белән нәтиҗәле «кара-каршы элемтә» тәэмин итү, территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерү һәм гражданнарны башка формалардагы җирле үзидарәне гамәлгә ашыруга (гамәлгә ашыруда катнашуга) җәлеп итү» номинациясе буенча.

Муниципаль берәмлекләрнең конкурс заявкалары, номинациясен һәм конкурста катнашучы категориясен күрсәтеп, муниципаль берәмлекләр башлыклары имзалаган бергә теркәп җибәрелә торган хатлар белән тапшырыла.

3.4. Муниципаль берәмлекнең конкурс заявкасы билгеләнгән вакытларны бозган, таләпләрне бозып тутырылган, комплектлы булмаган килеш тапшырылса, шулай ук анда дөреслеккә туры килмәгән һәм (яки) гамәлдә булмаган мәгълүматлар күрсәтелсә, әлеге Нигезләмәнең 3.3 нче пунктында күрсәтелгән органнар төзегән ярдәмче комиссияләр аны кабул итүдән баш тарта ала.

3.5. Ярдәмче комиссияләр конкурс заявкаларын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча 25 июньгә кадәр конкурс заявкаларында тиешле конкурс номинацияләре буенча иң яхшы муниципаль практика үрнәкләре чагылыш тапкан муниципаль берәмлекләрне билгеләү буенча карарлар кабул итә, һәм алар ярдәмче комиссияләрнең йомгак утырышларының тиешле беркетмәләре белән рәсмиләштерелә.

3.6 Ярдәмче комиссияләрнең йомгак утырышлары беркетмәләре һәм муниципаль берәмлекләрнең конкурс заявкалары конкурс комиссиясенә җиңүчеләрне билгеләү өчен 1 июльгә кадәр тапшырыла.

3.7. Конкурс комиссиясе 10 июльгә кадәр конкурсның тиешле номинацияләре һәм конкурста катнашучылар категорияләре буенча өч конкурс җиңүчесен билгели, һәм алар арасында конкурста катнашучыларның I – III урыннары бүленә.

3.8. Әлеге Нигезләмәнең 3.5 һәм 3.7 нче пунктларында күрсәтелгән карарларны кабул иткәндә, конкурс комиссиясе һәм ярдәмче комиссияләр әлеге Нигезләмәнең 3.1 нче пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең конкурс заявкаларын бәяләү методикасына таянып эш итә.

3.9. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар бирелә.

3.10. Конкурс комиссиясе тарафыннан «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының федераль этабында катнашу өчен сайланган муниципаль берәмлекләрнең конкурс заявкалары конкурс комиссиясе тарафыннан 20 июльгә кадәр «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсын оештыру һәм үткәрү буенча федераль конкурс комиссиясенә тапшырыла.

F:\KARAR\2017\313.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 27 май, 313 нче карары белән расланды

**«Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын оештыру һәм үткәрү буенча республика комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, комиссия рәисе |
| Шакиров Минсәгыйть Закир улы | «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе рәисе, комиссия рәистәше (килешү буенча) |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтов Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Борһанов Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Гарипов Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| Глухова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Зарипов Айрат Ринат улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Здунов Артём Алексеевич | Татарстан Республикасы икътисад министры |

| | |
|---|---|
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Сафин Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Фәйзуллин Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Фомин Анатолий Алексеевич | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Хәбибуллин Альберт Галимҗан улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры |
| Яһудин Шакир Шәяхмәт улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Якунин Леонид Александрович | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты рәисе (килешү буенча). |